КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 октябрь г.Казань № 909

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1339 нчы; 2023 ел, 11 ноябрь, 1464 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1582 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә, 1.5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

«в) транспорт чарасы юлда йөргән өчен түләү кертү тәртибен үтәү өлешендә төбәк әһәмиятенә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан һәм

гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларыннан, төбәк әһәмиятенә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының түләүле учатокларыннан транспорт чаралары йөрүне гамәлгә ашыруга карата;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин